СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2026 елның 18 феврале № 2

**«Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. « Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

9 статьяның 7 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы бистәсе, Заречная ур., 25 йорт, Үзәк ур., 12А йорт йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Лениногорск муниипаль районы
« Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Р.Ә.Мөхәмәтшина